ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

04.09.2024 № 823

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль берәмлекләр мәгариф педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 07 апрелендәге 398 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы икенче өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик тәкъдимнәр турында» 2024 елның 02 августындагы под-1381/24 номерлы боерыгы нигезендә, мәгариф эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль берәмлекләр мәгариф педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе

составындагы мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 07 апрелендәге 398 номерлы карары белән расланган Муниципаль берәмлекләр мәгариф педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә

түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче бүлектә:

1 пункт түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль берәмлекләрнең мәгариф бүлекләре (идарәләре) структурасындагы мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Айга база окладың күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы үткән затка “бакалавр”, “магистр” яисә “дипломлы белгеч” квалификациясен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 18405,0 |
| | | | | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 18410,0 |
| | | | | |
| | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә: муниципаль берәмлекләр мәгариф педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек мөдире (башлыгы) урынбасары;<br><br>Структур бүлекчә: муниципаль берәмлекләр мәгариф педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек мөдире (башлыгы); | - | - | 18481,0<br><br>18550,0 |

3.3 пунктның 10 абзацын:

«Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк тамгасы, «Телләр, мәдәниятләр, традицияләрне саклаган һәм үстергән өчен» күкрәк тамгасы, «Яшь мөгаллим» күкрәк тамгасы, «Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» аерымлык билгесе, «Мактаулы остаз» аерымлык билгесе, Россия Федерациясе мәгариф өлкәсе мактаулы хезмәткәре, Россия Федерациясенең балалар һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсендә мактаулы хезмәткәр, Мәгариф һәм агарту отличнигы, Россия Федерациясенең тәрбия һәм агарту өлкәсендә мактаулы хезмәткәре» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә.

Биектау муниципаль районы

Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин